Казан
(Идел буе)
федераль
университеты
газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№23
(74)

11 июль
2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

КФУның Кабул итү кампаниясендә эшнең иң кызган чагы. Бүгенге көнгә **УТЫЗ МЕҢНӘН АРТЫК ГАРИЗА КАБУЛ ИТЕЛГӘН**. Бу бер бюджет урынына – тугыз, түләүлегә өч кеше туры килә дигән сүз. Узган еллардагы шикелле, иң популяр бүлекләр булып Юридик факультет, Икътисад һәм финанс институты, Идарә итү һәм территориаль үсеш институты, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты тора.

• • • •

8 июль көнне Универсиада-2013 кысаларында университетның Альянс SAPы халыкара студентлар ярышы – **INNOJAM ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ МАРАФОНЫН ҮТКӘРДЕ**. Марафон Икътисад һәм финанс институты базасында оештырылды. Андый төр чара күп илләрдә һәрдаим үткәрелә. Казан InnoJamында катнашкан һәркемгә университетның Альянс SAP программасы буенча өстәмә белем алу мөмкинлеге биреләчәк. Җиңүчеләр исә 2013 елның ноябрендә Мәскәүдә уздырылачак SAP Forum UA чарасына чакыру алдылар.

• • • •

9 июль көнне **КФУ**да **ЛОДЗА УНИВЕРСИТЕТЫ** (Польша) белән **ВЕБИНАР БУЛДЫ**. Чара ике университетның хезмәттәшлеге нигезендә оештырылды. Видеокүпер КФУның Белем бирү ресурсларын үстерү департаменты тарафыннан оештырылды. Әңгәмә вакытында ике як студентлары геометрия өлкәсендә үткәргән тикшеренүләре нәтиҗәләре турында сөйләштеләр. Чара рус телендә үткәрелде. Алга таба мондый төр утырышларны инглиз һәм поляк телләрендә уздыру планлаштырыла.

• • • •

Яр Чаллы институтында беренче тапкыр «Менеджмент» юнәлешендә **«ТУРИЗМ» ПРОФИЛЕ БУЕНЧА ГАРИЗАЛАР КАБУЛ ИТӘЛӘР**. Математика, рус теле һәм җәмгыять фәненнән булган БДИ нәтиҗәләре буенча кабул иткән студентларны 4 ел эчендә берничә телдә сөйләшергә өйрәтәчәкләр, чит телдә практика үтү мөмкинлеге тудырылачак. Яр Чаллы институты бик күп чит ил уку йортлары белән хезмәттәшлек итә, шуңа күрә биредә Кытай, Испания һәм башка ил галимнәре килеп лекцияләр укый.

• • • •

7 июль көнне КФУның Кайгыртучанлык советы утырышлары залында РФ Мәгариф һәм фән министры **ДМИТРИЙ ЛИВАНОВ**, Казахстан республикасының Мәгариф һәм фән министры **БАКЫТҖАН ҖУМАГУЛОВ**, Белоруссия Республикасы мәгариф министры **СЕРГЕЙ МАСКЕВИЧ**, Кыргызстан республикасы мәгариф һәм фән министры **КАНАТ САДЫКОВ**, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры **ЭНГЕЛЬ ФӘТТАХОВ** һәм КФУ ректоры **ИЛШАТ ГАФУРОВ** катнашыында **КИҢӘШМӘ УЗДЫ**. Четрекле мәсьәләләр турында сөйләшкәндә, Д.Ливанов мәгариф системасының төп максаты югары уку йортларында белгечләр әзерлегенең дәрәҗәсен арттыру икәнен әйтте.

• • • •

7 июль көнне КФУның УНИКС мәдәниспорт комплексында РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Казан югары уку йортлары студентлары арасында **МИНИ-ФУТБОЛ** буенча **ДУСЛЫК МАТЧЫ УЗДЫ**. Кунаклар командасы исемлегендә РФ Мәгариф һәм фән министры Д.Ливанов, министр урынбасары А.Климов, Россия вузлары ректорлары һ. б. бар иде. Студентлар җыелма командасы составында Татарстан яшьләренең җәмәгать оешмалары вәкилләре уйнады. Нәтиҗәдә 5:6 исәбе белән кунаклар командасы җиңүгә иреште.

• • • •

7-16 июль көннәрендә Егор Гайдар фонды икътисадчылар өчен **GAIDPARK ҖӘЙГЕ ДИСКУССИЯ МӘКТӘБЕ ОЕШТЫРА**. Чарада Мәскәү өлкәсенең Химки шәһәренә Россиянең төрле шәһәрләреннән 120ләп студент җыела. Бу мәктәпкә эләгү өчен, конкурс аша үтәргә кирәк. Алабуга институтының икътисад һәм идарә факультеты студенты Роман Коваленко да GAIDPARK мәктәбе эшендә катнаша.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*









*Рәсемнәрдә: дзюдо буенча бакыр медаль иясе Мария Шекерова һәм көрәшче Илдар Гыйниятуллин*

# Универсиада башланды! Исәнмесез!

**XVII Җәйге Универсиада башланганга алты көн генә үтсә дә, без килгән кунакларны шәһәребез гүзәллеге, чарага әзерлекнең ни дәрәҗәдә югары булуы белән шакаттырырга, спортчыларыбызның чын профессионал икәнлекләренә төшендерергә өлгердек. Бүгенге көндә Россия җыелма командасы беренчелекне беркемгә дә бирми. Шул исәптән уку йортыбыз спортчылары да сынатмый.**

2013 елның 6 июле дөнья, Россия Федерациясе, Татарстан республикасы, аеруча Казан федераль университеты тарихында зур вакыйга булып истә калачак. Бу көнне Универсиада ачылышына кадәр бик мөһим чарага аерым тукталырга кирәк. Бөтен җир шарын урап, 104 мең км юл үткән Универсиада уты Казанга килеп җитте. Универсиада авылыннан башлап, иң тарихи уку йортының төп бинасына кадәр, Җиңү проспекты, Оренбург тракты, Павлюхин, Сәлимҗанов, Уң Болак, Ташаяк, Кремль урманары буенча, утны 55 факел йөртүче (барлыгы 2013), шул исәптән рәсми шәхесләр дә алып килде. Алар арасында КФУ вәкилләре дә, студентлары да бар иде. Утны сәхнәгә танылган теннисчы, дөнья чемпионы **Анастасия Мыскина** алып чыкты һәм КФУ ректоры **Илшат Гафуровка** тапшырды. Ут чараның рәсми ачылышына кадәр университетта сакланды. Бу уңайдан ректор, бик дулкынланып: «Бүген безнең иң бәхетле көн! Универсиада барышында барыбыз да актив булырбыз, дип ышанам. Ут эстафетасын да безнең уку йорты кысаларында төгәлләү юкка түгел. Университет үзенең фәнни мәктәпләре, мәшһүр галимнәре белән дан тота. Студентларыбыз халыкара дәрәҗәдә зур үрләр яулый. Һәр бишенче волонтер – безнең студент. Университетның Тарих музеенда сакланачак ут безгә һәрдаим бу зур чара турында искә төшереп торачак» – диде.

Кич белән мәркәзебезне генә түгел, бөтен Россияне, илне таң калдырган ачылыш тантанасы башланды. Анда Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин һәм башка мәртәбәле кунаклар катнашты. Үзенең оригинальлеге белән әлеге шоу Универсиада тарихында кабатланмас чара булып истә калыр, мөгаен. Юкка гына җитәкчеләр, 2024 елда узачак Олимпия уеннарын Казан уздырырга дәгъва кыла ала, дип, башкалабыздагы әзерлекне шулай югары бәяләмәде.

Күтәренке кәеф, җиңү атмосферасы белән башланган Студентлар ярышы шундый яхшы рухта дәвам итә. Беренче көннәрдән үк лидер булган Россия җыелма командасы югары үрләр яулавын дәвам итә. Безнең барлыгы 81 медаль бар, шуның 41-е алтын! (Газета басмага тапшырылган вакытта - *ред.*) Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институтының 3 курс студенты **Мария Шекерова** 78 килограммнан күбрәк авырлык категориясендә дзюдо буенча Универсиаданың бакыр медаль иясе булды.

Уку йортыбыз өчен тагын бер зур җиңү: шулай ук Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институтының 5 курс студенты **Илдар Гыйниятуллин** 70 килограммга кадәр авырлыкта билбау белән көрәш (классик стиль) буенча Универсиаданың алтын медаль иясе булды. Финалда безнең студент Төркмәнстаннан килгән Агамурат Оразсахедны җинде. Бронза медальләргә Молдавиядән Михаил Коничан һәм Украинадан Константин Тарасов ия булды.

Тагын бер атна һәм барлык борчумәшәкатьләр, дулкынланулар артта калачак. Ә хәзергә безне күп ярышлар, зур сынаулар һәм, әлбәттә, бөек җиңүләр көтә!

## • Бездә кунак бар

# Иске калыплардан арыныйк!

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

**8 июльдә КФУга АКШның Россиядәге Гадәттән тыш һәм вәкаләтле вәкиле Майкл Э.Макфол килде.**

**Майкл Макфол** – Стэнфорд университетының политология профессоры. Стэнфорд университеты каршындагы Гуверов институтында бирелә торган Питер һәм Хелен Бинглар стипендиясе иясе. Ул Фримен Сполья Халыкара тикшеренүләр институтының өлкән фәнни хезмәткәре. Бүген ул Президент Обама администрациясендә хезмәт күрсәтә.

**Ахыры 3нче биттә.**



Диана Поварова фотосы

• Галимнәребез

# Әйдәп баручы физиолог

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының (ТДГПУ) бай тарихында югары уку йортының данын күтәргән атаклы галимнәр күп булды. Шуларның берсе – профессор Осман Җамалетдин улы Курмаев.



✦ **Осман (Госман) Җамалетдин улы Курмаев** – физиолог, биология фәннәре докторы (1950), профессор (1951), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1968). 1934-1981 елларда Казан педагогия институтында зоология кафедрасы мөдире (1940-1946), кеше һәм хайваннар анатомиясе һәм физиологиясе кафедрасы мөдире (1950-1955; 1965-1974), проректор (1961-1965). Төп фәнни хезмәтләре нерв системасының һәм гуморaль факторларның йөрәк эшчәнлеген көйләү механизмнарын өйрәнүгә багышланган.

Казан физиологлар мәктәбенең әйдәп баручы физиологы О.Җ.Курмаевның хезмәт биографиясе, фәнни-педагогик һәм җәмгыяви эшчәнлеге үз халкына һәм иленә хезмәт итүнең ачык мисалы булып тора. 1920-1930 елларда ул Мордовия авылларының берсендә комсомол хәрәкәтен оештыра, күмәк хуҗалык төзүдә катнаша, белемгә омтыла, соңрак фәнни-тикшеренү эшләре, республика һәм СССР күләмендә Югары Совет депутаты сыйфатында җәмгать эшчәнлеге белән шөгыльләнә.

Осман Курмаев Пенза губернасының Саранск өязе Кривозерье волостена (хәзер Мордва республикасының Ләмбрә районына) караган Суркино авылында 1903 елның 28 декабрендә игенче гаиләсендә дөньяга килә. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, 6 ел авыл мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшли. 1926 елда Казанга килә һәм Шәрык педагогия институтына укырга керә.

Османның студент тормышы җиңел булмый. Үзенең хатирәләрендә ул болай искә ала: «Укуымның башлангыч чоры бик авыр шартларда үтте. Миңа тулай торактан караватсыз урын бирделәр. 2-3 атна идәндә йокладым, салкын тидереп, чирләп киттем, тик институтны ташламадым. Миңа стипендия билгеләсәләр дә, аны алу өчен институт директоры приказы Мәскәүдә расланырга тиеш, ягъни стипендияне ноябрь айларыннан да иртәрәк алу мөмкин түгел иде. Шул сәбәпле 2 ай бик авыр шартларда яшәргә туры килде. Ул вакытта ипинең кадагы – 6, ә төшке аш 10-15 тиен генә тора. Минем аның кадәр дә акчам юк иде. Вакытлыча эш табу да мөмкин түгел иде, чөнки ул чорда эшсезлек хөкем сөрде. Әти-әни дә ярдәм итәрлек хәлдә түгелләр, алардан сорап язарга кыймадым, чөнки мине алар ирексездән генә җибәрделәр бит. Ике күлмәгемнең берсен 50 тиенгә саттым, башка сатарлык әйберем юк иде».

Утызынчы елларда Осман Курмаев колхоз төзелешендәге ялгышларны төзәтергә Бөгелмә кантонына китә. «Кантон комитеты мине Шалты авылына җибәрде. Бер ай эчендә миңа авылдагы эшләрне жайга салырга һәм яңадан Ленин исемендәге колхозны оештырырга насыйп булды. Хәзерге вакытта ул Татарстанның Баулы районындагы алдынгы колхозларның берсе санала. Үткән елларда миңа, Казан университетының биология-туфрак факультеты каршындагы дәүләт имтиханы комиссиясе вәкиле буларак, шушы колхоз рәисенә университетны тәмамлау турында диплом тапшырырга туры килде. Бу минем өчен бик күңелле булды», – дип искә ала галим. Соңрак Осман Курмаев Казан дәүләт университеты каршындагы аспирантурада укый. Бу елларда физиология кафедрасында И.А.Аршавский, Я.С.Воронцов, М.А.Киселев кебек күренекле галимнәр эшли. О.Җ.Курмаев 1938 елда КДУның зоология һәм физиология кафедрасында кандидатлык диссертациясе яклый һәм аңа биология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә бирелә. Аның диссертациясе даими электр агымы йогынтысында экстракардиаль нервларның ярсыну күренешләре үзгәрүгә багышланган. Ул вакыттагы педагогия институтында бу – физиология буенча беренче диссертация була. Шушы чордан башлап, хәзерге физиологларның төп проблемасы булып, йөрәк физиологиясе, аның регуляциясе һәм онтогенетик планда төрле факторларга ияләшү (адаптация) мәсьәләләре тора. Педагогика университеты физиологлары мәктәбенә шушы вакытта нигез салынды дип санала.

1940 елда О.Җ.Курмаев зоология һәм физиология кафедрасы мөдире итеп билгеләнә.

Бөек Ватан сугышы елларында Осман Курмаев имгәнү (травма) шогыннан дәвалау проблемалары өстендә эшли. Сугыштан соң (1946 елда) ул, СССР Медицина фәннәре академиясенең мөхбир-әгъзасы А.В.Кибяков чакыруы буенча, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалына күчә һәм Биология институтындагы экспериментaль биология лабораториясендә докторлык диссертациясе өстендә эш алып бара. Шул ук вакытта педагогия институтында да укытуын дәвам итә.

1950 елда «Физиология» белгечлеге буенча татарлардан икенче булып (беренчесе – Ибраһим Вәлиди) докторлык диссертациясе яклый. Аның диссертациясе җылыканлыларның (этләрнең) йөрәгенә экстракардиаль нервлар йогынтысы механизмнарын өйрәнүгә багышлана. Ул, салкынканлылар өстендә тәҗрибәләр алып барган профессорлар А.В.Кибяков һәм А.А.Узбәков белән бер үк вакытта, гизүчән нервларның – йөрәккә тәэсир итүе ашказаны асты бизе функцияләренә, ә симпатик нервның бөер өстенең ми катламына бәйле булуын күрсәтә. Академик А.А.Ухтомский концепциясен үстереп, О.Җ.Курмаев тәҗрибәләр ярдәмендә симпатик һәм парасимпатик нервларның бәйләнеше үзара компенсацияләнүен раслый. 1950 елда О.Җ.Курмаев кеше һәм хайваннар анатомиясе һәм физиологиясе кафедрасын оештыра һәм аның мөдире итеп сайлана.

Осман Курмаев, чын профессор буларак, Татарстанның барлык югары уку йортларында диярлек фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче зур гына шәкертләр төркемен тәрбияләде. Ул таләпчән, катгый һәм гадел остаз булды, фән өлкәсендә фактларга гына ышанды һәм академик И.П.Павловның «фактлар ул – галим сулый торган һава» дигән сүзләренә таянды. Үзенең һәм шәкертләренең мәгълүматларын кабат-кабат тикшерә, нәшер ителгән басмаларга карата бик таләпчән иде. Басмага әзерләнгән мәкаләләрне берике атна тота, аннары төзәтергә кире кайтара иде. О.Җ.Курмаев 1974 елда кафедра мөдире вазифасын шәкерте – профессор Ф.Г.Ситдыйковка йөкләсә дә, профессор-консультант буларак, кафедрада актив эш алып барды. Ул Казан физиологлар мәктәбе тарихында бөтенләй яңа тикшеренү юнәлешенә – физик күнегүләр физиологиясенә нигез салучы булып кереп калды.

Осман Җамалетдин улы Казан шәһәр советы, СССР Югары Советы депутаты, Азия һәм Африка илләре бердәмлеге комитеты әгъзасы буларак та җәмәгать эшләре белән шөгыльләнде. Университет музеенда профессор О.Җ.Курмаев турында бай экспозиция тупланган.

*Мәгълүмат «Мәшһүр татар галимнәре» китабыннан алынды*

• Абитуриентлар өчен

# КФУда медицина үсеш ала

Ил күләмендә алдынгы юнәлешләрне булдыру максатыннан, Казан федераль университетында яңа проектлар, идеяләр тормышка ашырыла. Медицина һәм биологик технологияләр аеруча алга киткән өлкәләрдән санала. Бүгенге көндә Фундаментaль медицина һәм биология институтында яңа медицина кафедралары ачылды. Татарстанда медицина фәненең алга китешенә КФУда әзерләнгән белгечләр зур йогынты ясаячак. Алар яңа буын табиблары булачак. Ә уку йортының югары квалификацияле белгечләр әзерләү өчен, бөтен мөмкинлекләре дә бар. Әлеге институт бөтен төр белгечләр буенча табиблар, стоматологлар, табиб-генетиклар, табиб-рентгенологлар һ.б. әзерләүне максат итеп куя. Шулай ук Россиянең 200дән артык медицина оешмаларында, дөньяның иң яхшы фәнни үзәкләрендә стажировка үтү мөмкинлеге дә бар. Шулай ук «ФАРМА 2020» программасын тормышка ашыру кысаларында фармацевтика буенча фәнни-белем бирү үзәге ачылды. Биредә инновацион дарулар һәм субстанцияләр эшләп чыгару белән шөгыльләнәләр. Бу процесска химия, биология, медицина һәм фарматехнология буенча белгечләр җәлеп ителде.



**Фундаментaль медицина һәм биология институтының агымдагы юнәлешләре:**

- Медицина биохимиясе
- Медицина физикасы һәм биофизикасы
- Медицина кибернетикасы һәм информатикасы
- Гомуми һәм медицина генетикасы
- Медицина химиясе һәм фармакологиясе
- Медицина микробиологиясе
- Клиника эшчәнлеге
- Экспериментaль медицина өлкәсендә санаулы белгечләр - табиблар-тикшерүчеләр әзерләү.

Фән дөньясында иң мөһим һәм перспектив юнәлешләрнең берсе.

**Гомуми фәннәр комплексында инновацияне алга җибәрә алачак локоматив:**

- физика
- химия
- билогия
- мәгълүмати технологияләр

• Мөнбәр

# Интеллектуаль казанышлар мәйданы

**Фәрит ИМАМЕТДИНОВ,**
Фәнни-тикшеренү эшләре буенча әйдәп баручы инженер, НТТМ күргәзмәсендә КФУ делегациясенең җитәкчесе

22-29 июнь көннәрендә Мәскәүнең Бөтенроссия күргәзмә үзәгендә яшьләрнең НТТМ-2013 XIII фәнни-техник иҗаты күргәзмәсе оештырылды.



Әлеге күргәзмә – Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган интеллектуаль яшьләр форумы. Биредә 1100дән артык катнашучы барлыгы 600ләп фәнни-тикшеренү проекты тәкъдир итте. Экспонентлар арасында Камчаткадан алып Калининградка, Вологдадан – Төньяк Кавказга кадәрге территориядә урнашкан 210 югары, урта, урта махсус белем бирү учреждениеләре бар иде. Күргәзмәдә Татарстан данын КФУның 2 проекты һәм Республика мәктәптән тыш эш үзәге эшләнмәләре яклады. Университетыбызның Фундаментaль медицина һәм биология институтыннан **Олег Аникеев** һәм **Гөлнур Дәүләтшина** проектлары югары фәнни дәрәҗәсе, актуальлеге белән аерылып торды. Бу хакта конференциянең фәнни комитеты да билгеләп узды. НТТМ Бөтенроссия конкурсының иң дулкынландыргыч мизгелләре, әлбәттә, җиңүчеләрне бүләкләү өлеше булды. КФУ НТТМ-2013 күргәзмәсе дипломына лаек булды. Фундаментaль медицина һәм биология институтының биохимия кафедрасы аспиранты Олег Аникеев «Генетик анализ өчен практика тарафыннан таләп ителгән ДНК бүленеп чыгу ысулы» дип аталган проекты белән «Фәнни-техник иҗаттагы уңышлары» өчен Бөтенроссия күргәзмә үзәгенең алтын медале, ә V Халыкара конференциясе нәтиҗәләре буенча «Куелган максатка ирешүдә оригинaль яктан якын килгәне» өчен кыйммәтле приз белән бүләкләнде. (Фәнни җитәкчесе: биохимия кафедрасы доценты Ольга Кравцова). Шул ук институтның микробиология кафедрасының 4 курс студенты Гөлнур Дәүләтшина исә «Наноматериаллар. Алар куркынычсызмы?» проектын тәкъдир итеп, шулай ук җиңүгә иреште. Гөлнур наноматериалларның тулы тере организмга ничек тәэсир итүен өйрәнгән. Ул сәләтле яшьләргә ярдәм итү өчен бирелә торган премиягә лаек булды.

Алай гына да түгел, аның проекты РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының электрон мәгълүмати каталогына сайлап алынды. Аннан тыш, проектын яклаганнан соң, Гөлнур У.М.Н.И.К гомумроссия конкурсының финалистлары исемлегенә кертелде һәм диплом белән бүләкләнде (фәнни җитәкчесе: биология фәннәре докторы, микробиология кафедрасы доценты Равил Фәхруллин). Җиңүчеләрне мондый югары күрсәткечләре белән чын күңелдән котлыйбыз!

Хезмәттәшлек

# Яңа «чылбыр» булдырдык!

Дания ФАТЫЙХОВА,
хәбәрче

7 июль көнне КФУда федераль университет ректорлары семинары үтте. Чара РФ Мәгариф һәм фән министры Дмитрий Ливанов җитәкчелегендә узды.

Семинар нәтиҗәсе буларак, ректорлар федераль университетлар чылбыры булдыру турындагы килешүгә кул куйдылар. Әлеге документ фәнни-мәгариф, инновацион эшчәнлек сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген үстерү максатыннан көчләрне берләштерер дип көтелә.

Әлеге килешү федераль университетлар өчен әһәмиятле булган проблемаларны хәл итү һәм үсеш перспективаларын билгеләү максатыннан гамәлгә ашырылды. И.М.Ломоносов ис. Төньяк (Арктик) федераль университеты ректоры **Е.Кудряшева** үзе җитәкли торган университетта июнь башында уздырылган «Федераль университетларның үсеш перспективасы» киңәшмәсенең нәтиҗәләре белән таныштырды. Аның әйтүенчә, очрашуда университетларның үсеш программаларына кертелергә тиешле төзәтмәләр, әлеге уку йортлары базасында дүрт проект эшчәнлеге – федераль университетларның челтәрле бәйләнешен үстерү, вузлар үзгәртеп коруны һәм мобиль эрелләштерүне анализлау, бөтен Россия мәктәп балалары һәм студентлар өчен олимпиадалар оештыру һәм үткәрү, белем бирү системасында яңа документлар апробациясе өчен махсус мәйданчыклар булдыру турында сүз барган.



Диана Поварова фотосы

КФУ ректоры **И.Гафуров** РФ Мәгариф һәм фән министрлыгына югары уку йортларына матди өлеш кертү бизнесы өчен мотивация булдыру, төбәкләргә федераль университетларны турыдан-туры финанслау мөмкинлеге тудыру, тигез хокуклылык шартларында эре компанияләр белән уртак проектлар һәм коллектив файдалану үзәкләре булдыруга теләктәшлек итү үтенече белән мөрәҗәгать итте. Ректор, шулай ук, гуманитар фәннәр өлкәсендәге тикшеренүләр өчен дәүләт заказы булдыруның мөһимлегенә басым ясады.

**Дмитрий Ливанов** федераль университетлар челтәрен булдыруны хуплады һәм әлеге проектны гамәлгә ашыру өчен билгеле вәкаләтләр белән тәэмин итәргә сүз бирде: карар кабул итү механизмы министрлык дәрәҗәсендә эшкәртеләчәк.

Министр сүзләренчә, һәр федераль университет үзенең үсеш программасын биш ел эчендә гамәлгә ашыра, шул еллар арасында куйган максатларга ирешергә тиеш. Финанслау вузларның хәзерге эшчәнлеге нигезендә алып барылачак һәм ул үсеш программасына караганда да отышлырак булырга мөмкин.

Федераль югары уку йортларын төбәк средстволарыннан финанслау мәсьәләсенә килгәндә, министр андый схема булдыру мөмкинлеген кире кагмады. Д.Ливанов фикеренчә, монда ярдәм формат тәкъдим итү кыенрак булачак. Шуңа да карамастан, ул бу мәсьәләне хәл итү юлларын эзләргә сүз бирде.

Федераль университет ректорлары семинарының чираттагы утырышы 4-5 октябрьдә Балтик федераль университеты базасында булачак.

Уртак җиңү



# Лаеклы субсидия

Шушы көннәрдә КФУ халыкара рейтингларда югары уку йортларының дәрәҗәсен күтәрү буенча махсус субсидия алу хокукын бирә торган конкурста җиңү яулады.

Әлеге нәтиҗә 5-6 июль көннәрендә бөтендөнья фәнни-белем бирү үзәкләре арасында РФнең әйдәп бара торган университетларының конкурентлыгын арттыру советы утырышында кабул ителде.

Россия хөкүмәте карары нигезендә, 2013 елда Россиянең әйдәп бара торган университетларының конкурентлыгын арттыруның гомуми бюджеты 9 миллиард сум тәшкил итәчәк.

Вузларның халыкара рейтингларын күтәрү өчен, чит ил югары уку йортлары белән уртак проектлар булдыру, безнең студентларны укыту өчен чит ил профессорларын җәлеп итү, студентлар һәм укытучылар өчен халыкара академик мобильлекне арттыруны гамәлгә ашырырга кирәк булачак.

Конкурсның сайлап алу турына барлыгы 54 гариза кабул ителгән, төп өлешкә шуларның 36сы узган. Университетларны сайлаганда, югары уку йортларында фәнни эшчәнлекнең үсеш дәрәҗәсе, абитуриентлар өчен әзерләнгән белем бирү программаларының кызыклыгы, вузның халыкара академия базарына җәлеп ителүе, халыкара университетлар рейтингындагы позицияләре исәпкә алынган.

Утырышта халыкара университет рейтингында югары урынга күтәрелү өчен каралган таләпләр программалары белән Россия университетларының 36 ректоры чыгыш ясады. Шулар арасыннан совет куелган таләпләргә туры килгән 15 вузны сайлап алды һәм аларга тиешле субсидия биреләчәк.

Җиңү яулаган 15 университет арасында, **Идел буе федераль университетыннан** тыш, **Ерак көнчыгыш федераль университеты, Россиянең беренче Президенты Б.Н.Ельцин ис. Урал федераль университеты** да бар.

Бездә кунак бар

# Иске калыплардан арыныйк

Башы 1нче биттә.

Очрашу алдыннан Татарстан массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен пресс-конференция үткәрелде. Аның барышында вәкил Универсиада ачылышына гаиләсе белән килгәнлеген белдерде. Универсиаданың ачылыш тантанасына караган сорауларга җавап биргәндә, **Майкл Э.Макфол** әлеге тамашаның кин колачлы булуы һәм, гомумән, Татарстанның ничек итеп Универсиадага әзерләнүенә соклануын белдерде. Вәкилнең Казанда өченче мәртәбә булуы икән. Соңгы тапкыр – моннан өч ел элек. Майкл Э.Макфол шул вакыт эчендә республика башкаласының гаҗәеп дәрәҗәдә яхшы якка үзгәрүен билгеләп узды.

АКШ вәкиле фикеренчә, Универсиада кебек зур вакыйга үзенә бөтен дөньяга күрсәтү, Татарстанны таныту өчен менә дигән мөмкинлек. Ә Казан белән Татарстанның күрсәтерлек әйберләре бар. АКШта, мәсәлән, Татарстанны бизнеска җавапы карый торган төбәк буларак беләләр икән.

Майкл Э.Макфолның КФУга визитының төп максаты исә, университетта төрле еллларда АКШ Дәүләт департаментының мәгариф һәм мәдәни программалары юнәлеше буенча финанслана торган халыкара студентлар алмашу программасы буенча белем алган кешеләр һәм Казанда рус телен өйрәнә торган АКШ студентлары һәм өлкән укучылары белән очрашып сөйләшү иде.



Диана Поварова фотосы

Дипломат фикеренчә, Россиядә эшләп карамаган күп кенә компанияләр илгә иске шаблон буенча бәя бирә. «АКШның Россиядәге вәкиле буларак, төп бурычымны негатив калыплардан арынру, хезмәттәшлеккә мөмкинлекләрне арттыру буларак билгелим. Әмма бу гына аз. Сезнең һәммәгез шундый вәкил булырга тиеш: үзегездә булган уңай күренешләр турында сөйләргә оялмагыз, үз-үзегезне рекламалагыз, чөнки икътисад, фән, мәдәният, җәмгыять үзе дә акыллар бәйләнеше, акыл хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә генә үсә ала», – дип белдерде. Әлеге фикер очрашу буена кызыл җеп булып сузылды. Рус һәм инглиз телләрендә сорауларга җавап биргәндә һәм аларны шәрехләгәндә, вәкил берничә мәртәбә кабатлады: «АКШка килсәгез, үзара якыная вәкилләре булыгыз, үзегезне һәм илегезне алга җибәрү турында уйлагыз!»

Очрашуда глобаль мәсьәләләргә караган сораулар да бирелде. Мәсәлән, АКШ һәм Россия арасындагы үзара ышанычны ныгыту һәм аның нәтиҗәсендә икътисади хезмәттәшлекне үстерү перспективалары бармы? Бу сорауга җавап биргәндә, Майкл Э.Макфол АКШта Россиядә булган һәм бүген дә үсеп килүче урта классның өметләр зур булуы хакында әйтеп узды. Вәкил бу класска караган кешеләрнең дөньяви трендлар үсешен тоеп һәм аңлап эш итүен һәм үз өстенә җаваплылык ала белүен билгеләп узды.

Очрашу барышында Майкл Э.Макфолга халыкара студентлар алмашу программасы буенча белем алган шәкертләрдән АКШның әйдәп баручы югары уку йортларында уку мөмкинлеге тудырганы өчен бик күп рәхмәт сүзләре ишетергә туры килде.

Сөйләшү тәмамланганнан соң, АКШ вәкиле Казан университетының Тарих музее белән танышты һәм КФУ ректоры **Илшат Гафуров** белән формаль булмаган рәвештә чәй өстәле артында очрашып сөйләште.

Белми калма!

# Каләмең көчле булсын, дисәң

**Казан (Идел буе) федераль университетының Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты «Журналистика» юнәлешендә «Иҗтимагый-сәяси татар журналистикасы» программасы буенча укучылар кабул итә.**

Магистратурага югары белемгә ия булган (гуманитар белем булса бигрәк тә яхшы) һәм сәяси журналистика белән кызыксынган яшьләр чакырыла.

Магистратурада **уку срогы** – **2 ел**. Укучылар тулай торак белән тәэмин ителә. Бюджет бүлегендә укучылар **стипендия** дәвала. Уку графигы эшләп белем алучыларның мәнфәгатьләрен күздә тотып төзелә.

**Гаризалар 25 июльгә** кадәр кабул ителә. **29 июльдә** укырга теләк белдерүчеләр белән әңгәмә формасында **имтихан** оештырыла. Барыгызны да көтеп калабыз!

*Татар журналистикасы кафедрасы*

• Универсиада-2013

# Мең урадым Казан урамын!

Алинә САДЫЙКОВА, хәбәрче

Шәһәребезнең тарихи урынннары белән кызыксынган, биеклектән, җил тизлегеннән курыкмаган, һәрвакыт вакыйгалар үзәгендә булырга яратучылар өчен шәп яңалык: Казаныбызда ике катлы туристлар автобусы йөри башлады!

Әлеге автобуслар һәр теләгән кешене башкала үзәгенең тарихи һәм истәлекле урыннары буенча йөртә һәм таныштыра. Ике катлы «атлар» бер сәгать дәвамында Иске Татар бистәсе, Казан Кремле, Казансу яр буе, Ирек мәйданы, Бауман урамнары аша экскурсия үткәрә. Соклануны яшерә алмаган әлеге проект хезмәткәре: «Мондый экскурсияләр Россиянең Мәскәү һәм Казан шәһәрләрендә генә бар. Бүгенге көндә шәһәрдә ике автобус йөри. Минемчә, бу туристлар өчен генә түгел, ә Казан халкы өчен дә бик отышлы һәм файдалы проект. Шәһәрегез бик матур, чиста һәм, чын мәгънәсендә, горурланып күрсәтә алырлык урыннарыгыз бик күп», – дип, фикерләре белән уртаклашты.



Мондый мөмкинлектән читтә калырга ярамый дип, без дә ике катлы автобуста йөреп карарга булдык. Беренче көн булганлыктан, автобусларның берсе хезмәт күрсәтте, ә икенчесе фотога төшү, телевизион тапшырулар әзерләү, кыскасы, реклама буларак эшләде. Ике катлы каретаны көтеп торган арада, шәһәребезнең гадәти маршрутлы автобус кондукторлары һәм йөртүчеләре дә махсус туктап, аның янында фотога төштеләр. Гаҗәп кызык күренеш иде бу!

Көн бик эссе булганлыктан, без икенче катка менеп «кунакладык» та, аудиоэкскурсияле сәяхәтебезне башлап җибәрдек. Икенче каттан караганда, Казан тагын да матуррак икән: бер яктан ул шундый зур – колачлап бетергесез, икенче яктан – уч төбенә сыеп бетәр кебек тоела! Аудиоэкскурсия татар, рус, инглиз, испан, алман, француз, кытай һәм төрек телләрендә хезмәт күрсәтә. Мәгълүматның татар җырлары белән үрелеп баруы аеруча җанга рәхәт.

Экскурсия вакытында Казан университетының күп кенә биналары яныннан үттек. Колакчыннар аша диктор уку йортыбыз турында шактый тулы мәгълүмат бирде. Туган университетым турында яңа һәм кызыклы фактлар белдем. Чит илдән килгән кунаклар уку йортыбыз белән якыннан танышa алачак, дип сөендем. Безнең белән бер рейска кузгалган чит шәһәр кызлары университетка гашыйк булуларын шунда ук белгерттеләр! Төп бина яныннан узганда, алар хис-кичерешләрен яшерә алмадылар.

Ирина белән Катя Пенза шәһәре кызлары булып чыктылар. Алар Универсиада вакытында спортчыларны һәм волонтерларны Мегафон операторына тотыштырып йөрүчеләр икән. «Казан безгә бик ошады, зур һәм тарихи шәһәр. Безнең Пенза шәһәре кечкенәрәк, шуңа да барасы җиребезгә тиз барып җитәбез. Ә Казанда юлга бик күп вакыт китә, шунысы гына бераз кыенлык тудыра. Тулаем алганда, шәһәрегезнең истәлекле урыннары, тарихи һәйкәлләре, үзенчәлекле биналары безне таң калдырды», – диде кызлар.

Шәһәрнең матурлыгына соклану белән беррәттән, экскурсия барышында үзең өчен күп яңалык аласың, булган белемнәрне яңартасың. Универсиада уңаеннан тудырылган заманча мөмкинлекләрдән дөрес файдаланып, аларны үз кулларыбыз белән җимермичә, саклый белсәк иде!

*P.S. Маршрут барлыгы 10 тукталыштан тора. **Билет бәясе – 400 сум (студентларга – 300 сум).** Билет 24 сәгатькә кадәр яраклы. Автобуска утыргач, теләгән тукталышта төшеп калып, бер тәүлек эчендә сәяхәтне дәвам итәргә мөмкин.*



# Изге гамәлләр кылыйк

9 июльдә мөселманнар изге Рамазан аена керде.

Бу – Аллаһка табыну һәм рухи яктан чистарыну ае. Гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә, ураза «тыелып тору» дигәнне аңлата. Шәригать кануннары буенча, мөселманнар Рамазан аенда, иртән кояш чыкканнан алып, кояш батканчыга кадәр ризыктан, судан, буш сүздән, ялганнан, гайбәт сөйләүдән, монафикълыктан тыелып торырга тиешләр. Уразаның төп максаты: рухи яктан чистарыну. Бу айда изге «кадер кичәсе» дә бар. Шушы көнне кылган күркәм гамәл бигрәк тә саваплы, мең гамәлгә тиң булачак. Изге Рамазан аенда ифтар мәҗлесләре үткәрү күркәм гадәт. Авыз ачтыруның савабы зур. Бер ай ураза тотканнан соң, 8 августта Гает бәйрәме булачак.

Сүз уңаеннан, Универсиада Халыкара мәгълүмат үзәгендә Диннәр үзәге эшли башлады. Анда православлар, мөселманнар, католиклар, протестантлар, иудейлар, буддистлар гыйбадәт кылачак. Һәрберсе өчен аерым бүлмәләр әзерләнгән. Имам итеп исә үзәктә Малайзия Ислам университетын тәмамлаган, татар, рус, инглиз, гарәп телләрендә сөйләшүче Исмәгыйль Зыятдинов билгеләнгән. Диннәр үзәге 20 июльгә кадәр тәүлек дәвамында ачык торачак.

Материалларны **Илмир ВӘЛИЕВ** әзерләде, гимнастика үзәге волонтеры

# Алтын гимнастика

7 июль көнне гимнастика үзәгендә Россиянең спорт гимнастикасы буенча җыелма командасы: Алия Мустафина, Татьяна Нәбиева, Ксения Афанасьева, Анна Дементьева, Мария Пасека – башка призерларны күпкә артта калдырып, беренчелеккә чыкты. Япония командасы – икенче. Универсиада бакыры Германия җыелма командасына әләкте.

Безнең кызлар искиткеч матур, онытылмас чыгыш ясадылар. Әлегәчә Универсиада тарихында мондый көчле команда 1973 елда (Мәскәү) күзәтелә. Быелгы команданың сынатмаячагы да көн кебек ачык. Спортчы кызлар безгә үз фикерләрен әйтте.

**ТАНЯ НӘБИЕВА:** «Озак вакыт үземнең карьера турында уйландым: алга таба гимнастика белән шөгыльләнүнең мәгънәсе булырмы икән? Ләкин, тәүге җиңүдән соң, миндә яңа дәрт һәм теләк кабынды. Алга таба да шөгыльләнеп, яңа үрләр яулыйсы килә башлады. Әлеге җиңү өчен тренерларыма, дусларыма, якыннарыма рәхмәт әйтәсем килә».

**КСЕНИЯ АФАНАСЬЕВА:** «Минемчә, барысы да уңышлы узды. Барыбыз да әйбәт чыгыш ясадык. Бу чын прогресс. Мин үземнән бик канәгать калдым».

**МАРИЯ ПАСЕКА:** «Мин бу нәтиҗәгә бик шатмын. Әлбәттә, аз гына хаталар да булды. Гомумән алганда, барысы да әйбәт килеп чыкты һәм без җиңдек! Җанатарларга зур рәхмәт. Аларның уңай энергетикасы безгә көч биреп торды».

Россия гимнасткалары өчен төп ярышлар сентябрьдә Антверпен (Бельгия) шәһәрендә узачак. Бирелә гимнастика буенча дөнья чемпионаты старт алачак.

8 июль көнне шул ук залда ир-атлар командалары көч сынашты. Монда да безнекеләр сынатмады. Россия командасы: Эмин Гарибов, Денис Абляҗин, Николай Куксенков, Давид Белявский, Никита Игнатьев, уңышлы чыгыш ясап, кабат алтын медальгә ия булды. Украина командасы – 2, ә Япония җыелмасы 3 урынны алды.

Барлык спортчыларыбызга тагын да зур җиңүләр телибез.








Универсиада спортчылары үзләрен физик яктан гына түгел, ә рухи яктан да югары дәрәҗәдә күрсәтә. Аларның физик мөмкинлекләренә сокланмый мөмкин түгел. «Дөрес туклану – сәламәтлек һәм көч чыганагы» дигән сүзләрне истә тотып, Универсиада волонтерларын да спортсменнарныкы кебек үк туклыклы һәм файдалы төшке аш белән тәэмин итәләр.

# Яхшы эшкә – ланч-бокс!




15 минут эчендә әзер була торган төшке аш дигәннәре – «Горячий обед» ланч-бокслары. Кәгазь савыттагы төшке ашны микродулкынлы мич һәм плитәдән башка махсус технология ярдәмендә теләсә кайсы урында җылытып ашарга була. Әлеге ланч-бокслар «Конкорд. Кулинарная линия» компаниясе тарафыннан җитештерелә. Төшке ашлар үзләренең кыйммәтле сыйфатларын югалтмыйча бер елга кадәр сакланырга мөмкин. Барысына да сыек азот сәбәпче. Җитештерү вакытында сыек азот кулланганга күрә, продукция шундый озак вакыт бозылмый. Ланч-боксның авырлыгы – 350 грамм. Шуларның 200 граммы гарнир, 150 граммы – ит. Туклану бертөрле генә түгел, ә ассортиментта 35 төрле ланч-бокс бар.

Кулланылышта уңайлы булган төшке аш барлык волонтерларга да көч бирә һәм позитив эшкә юнәлдерә.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълумати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылгa кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ЖҖЧ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.